**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

РЕШЕНИЕ КАРАР

2 нче ноябрь 2024 ел №10

Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 маендагы 6 номерлы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кәүҗияк авыл җирлеге советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге Советы 6 номерлы 18 май 2020 елгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасында "тапшыра" сүзеннән соң "түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча"сүзләрен өстәргә.;

2) 5 статьяның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:: "- Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын билгели;"
3) 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"туристлык салымы-100 процент норматив буенча.»;

2. Әлеге карарның 1 пунктның 2 пунктчасы 01.01.2025 елдан үз көченә керә..

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башлыгы Ф.Ә.Хөснетдинов